**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №310-41 «12» декабрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2014 елның 10 апрелендәге «Азнакай муниципаль районында вакантлы идарә итү вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында»гы карары белән расланган Азнакай муниципаль районында вакантлы идарә итү вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә нигезендә, Азнакай шәһәр прокуратурасының 2019 елның 29 ноябрендәге 02-01-19/1519-519 номерлы «Ачыкланган коррупциоген факторны бетерү максатыннан норматив хокукый актны үзгәртү турында»гы таләбен исәпкә алып

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2014 елның 10 апрелендәге «Азнакай муниципаль районында вакантлы идарә итү вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында»гы карары белән расланган Азнакай муниципаль районында вакантлы идарә итү вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 бүлектәге 8 пунктта «кирәк очракта комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 4 бүлекнең 10 пунктындагы 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) комиссиянең еллык эш планын раслый һәм аңа үзгәрешләр кертә;».

2. карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»

түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http: //aznakayevo. tatar. ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис М.З. Шәйдуллин